**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2025 елның «15» октябреннән № 2-12

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 30 сентябрендәге 14-105 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 14-105 номерлы карары белән (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2022 елның 29 декабрендәге 30-238 номерлы, 2023 елның 16 мартындагы 32-247 номерлы, 2023 елның 10 ноябрендәге 38-307 номерлы карарлары редакциясендә) расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Нигезләмәнең 16 статьясындагы 5 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару территориясе;».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы Е.А. Тарнавский